МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

29.01.2025 Казан ш № 43

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә социаль хезмәтләрдән файдалануга гражданнар чиратын формалаштыру һәм алып бару тәртибен раслау турында» 2020 елның 3 июлендәге 484 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә социаль хезмәтләрдән файдалануга гражданнар чиратын формалаштыру һәм алып бару тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә социаль хезмәтләрдән файдалануга гражданнар чиратын формалаштыру һәм алып бару эшен камилләштерү максатларында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә социаль хезмәтләрдән файдалануга гражданнар чиратын формалаштыру һәм алып бару тәртибен раслау турында» 2020 елның 3 июлендәге 484 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2021 елның 24 февралендәге 100 номерлы, 2022 елның 27 гыйнварындагы 58 номерлы, 2024 елның 25 июнендәге 442 номерлы боерыклары керткән үзгәреше белән) белән расланган Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә социаль хезмәтләрдән файдалануга гражданнар чиратын төзү һәм алып бару тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.9 пунктта:

«телефонга» сүзләреннән соң «, телефон буенча» сүзләрен өстәргә;

«баш тарту нигезен (нигезләрен) күрсәтеп.» сүзләрен өстәргә;

3.2 пунктның икенче абзацында «телефонга» сүзләреннән соң «, телефон буенча» сүзләрен өстәргә;

күрсәтелгән Тәртипкә 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә социаль хезмәтләрдән файдалануга гражданнар чиратын формалаштыру һәм алып бару тәртибенә 1 нче кушымта (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү министрлыгының 29.01.2025 ел, № 43 боерыгы редакциясендә)

форма

______________________________________________
(социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең исеме)
______________________________________________

______________________________________________
(гражданинның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туу датасы)
______________________________________________
(яшәү урыны)
______________________________________________
______________________________________________
(элемтә өчен телефоны, электрон почта адресы (булган очракта))

кемнән
____________________________________________ [1]
(законлы вәкилнең, башка ышанычлы затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))
______________________________________________
(вәкилнең вәкаләтләрен, вәкилнең шәхесен, яшәү урыны адресын раслаучы документның реквизитлары)

______________________________________________
______________________________________________

______________________________________________
(элемтә өчен телефоны, электрон почта адресы (булган очракта))

## Социаль хезмәтләрдән файдалануга исәпкә кую өчен гариза

Исәпкә куюны сорыйм

мине[2], ______________________________________________________________
(фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта))

гражданинны[3]

______________________________________________________________________
(гариза бирелгән гражданинның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) күрсәтелә)

социаль хезмәтләрдән файдалану өчен ______________________________________

______________________________________________________________________
(социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең исеме күрсәтелә),
______________________________________________________________________
бүлекчә исеме (кирәк булганда)

социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә ______________________________________.
(социаль хезмәт күрсәтү рәвеше күрсәтелә)

Әлеге мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын раслыйм.
Гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

| т/с | Документ исеме | Саны | |
|---|---|---|---|
| | | данә | бит |
| 1. | | | |
| 2. | | | |
| ... | | | |

Социаль хезмәтләрдән файдалануга исәпкә кую турында яисә социаль хезмәтләрдән файдалануга исәпкә куюдан баш тарту турында, социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасының гамәлдә булу срогы тәмамлану турында, чираттан төшереп калдыру турында хәбәр алуга риза:

почта адресы буенча язма рәвештә:

_______________________________________________________________

телефон аша:_____________________________________________________

телефонга смс-хәбәр белән:_______________________________________

электрон почта адресы буенча электрон документ формасында:

_______________________________________________________________

Миңа нинди дә булса үзгәрешләр очрагында (адрес, телефон һ.б.) бу хакта оешмага хәбәр итәргә кирәклеге турында хәбәр ителде.

Социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучылар реестрына кертү өчен[4] «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль законның 9 статьясы нигезендә үзем турында (үзенә карата гариза бирелә торган гражданин турында) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә______________.

(риза/риза түгел)

______________(___________________________) «___» ______________ ел.

(имза) (Ф.И.А.) (гаризаны тутыру датасы)

---

[1] Әлеге позиция гаризаны гражданинның законлы вәкиле, башка ышанычлы заты биргән очракта тутырыла.
[2] Әлеге позиция социаль хезмәтләрдән файдалануны сорап мөрәҗәгать иткән гражданин гариза биргән очракта тутырыла.
[3] Әлеге юл гаризаны гражданинның законлы вәкиле, башка ышанычлы заты биргән очракта тутырыла.
[4] Кирәклесен ассызыкларга.